Tatar16.ru

# Абдулла Алиш
# (1908 – 1944)

*« Сатмас егет илен алтын*
*көмешләргә,*
*Әгәр югалтмаса вөҗданын.*
*Алтынны ул чүпкә санар,*
*Иң кыйммәтле күрер*
*Ватанын »*



- *Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1908 елның 15 сентябрендә Татарстан АССРның Куйбышев районы (элекке Казан губернасы Спас өязе) Көек авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Абдулла алты-җиде яшьләрендә этисеннән укырга-язарга өйрәнә, авылда башлангыч белем ала, ә 1917 елда этисе аны үзләреннән*


Tatar16.ru

- *15 чакрымдагы Ямбакты мәдрәсәсенә илтә. А. Алиш аны 1919 елда тәмамлап, 1921 елга чаклы Бураково авылындагы яңа ачылган совет мәктәбендә, 1927 елга кадәр Спас (хәзерге Куйбышев) педагогия техникумы каршындагы җидееллык рус мәктәбендә укый.*

Tatar16.ru

- *Шушы елларда ул әдәби иҗат өлкәсендә каләмен сыный башлый.*
- *1927 елның җәендә ул Казан Җир төзү техникумына укырга керә. 1930 елда аны уңышлы тәмамлап, шул елның көзенә кадәр Минзәлә кантоны җир төзү бүлегендә мелиоратор булып эшли.*
- *1931 — 1933 елларда А. Алиш Казандагы 1 нче ТЭЦ төзелешендәге гидротехника буенча десятник,*





Tatar16.ru

- *Журналга җаваплы секретарь булып эшкә килә. 1937 елдан алып Бөек Ватан сугышына кит-кәнче «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналында һәм Татарстан радиокомитетында эшли. Шул ук елларны эштән аерылмыйча Казан дәүләт*

- педагогия институтының кичке бүлегендә укый. Язучының иҗаты ачылып, аның төп әсәрләрен язуы да нәкъ шушы чорга туры килә. Ул 1939 елда СССР Язучылар союзына член итеп алына.
- Бөек Ватан сугышына А. Алиш 1941 елның июлендә китә, солдат-радист буларак Орлов өлкәсендә барган каты сугышларда катнаша. 1941 елның 12 октябрендә Десна елгасының Брянск

Tatar16.ru

- шәһәре урнашкан тирәсендә чолганышта кала һәм фашистлар кулына әсир төшә. Фашистлар аны 1941 елның кышында Литвадагы хәрби әсирләр лагеренда тотканнан соң, 1942 елның язында Чехословакиядәге Сандау шәһәренә озаталар. Аннары ул Польшадагы Седльце шәһәренә һәм,

- *ниһаять, Берлин янындагы Вустрауга килеп эләгә. Куркусыз йөрәкле совет солдаты һәм язучы Абдулла Алиш шушында үзенең якын каләмдәше, тоткынлыкта яшерен антифашистик эш алып баручы Муса Җәлил һәм җәлилчеләр белән очраша, үзе дә актив рәвештә яшерен оешма эшендә катнаша башлый. 1943 елның августында яшерен оешманың эше һәм аның членнары фашистлар тарафыннан*

Tatar16.ru

- *фашистлар тарафыннан фаш ителә һәм башка җәлилче-ләр белән бергә Абдулла Алиш та 1944 елның 25 августында гильотинада җәзалап үтерелә.*